ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ **КАРАР**

14 ноябрь 2024ел № 7582

Башкарма комитетның «Муниципаль контроль төрләре буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 22 сентябрендәге 8869 номерлы Карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 21 февралендәге 19/8 номерлы Карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Муниципаль контроль төрләре буенча чаралар үткәрүгә җәлеп ителә торган экспертларны аттестацияләү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 2023 елның 22 сентябрендәге 8869 номерлы Карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) административ регламентта:

- 2.4.4. пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.4.4. Аттестациянең гамәлдә булу срогы, түбәндәге очраклардан тыш, 5 елдан да ким була алмый:

1) аттестация контроль (күзәтчелек) чарасын (бер тапкыр үткәрелә торган аттестация) үткәрү срогына билгеләнгәндә (кирәк булганда);

2) аттестация сроксыз характерга ия булганда (сроксыз аттестация) (кирәк булганда).»;

2) карарга 3 нче кушымтаның 3 пунктында:

- түбәндәге эчтәлектәге 1 пунктча өстәргә:

«1) экспертизалар өлкәсенә туры килә торган профиль буенча кимендә 5 ел эш стажы;»;

- 1-5 пуктчаларны 2-6 пунктчалар дип исәпләргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесенең беренче урынбасары И.С. Зуевка йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов